# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

Бураково авыл җирлегенең Коминтерн торак пунктында

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының

2024 елның 27 ноябрендәге 2 номерлы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Бураково авыл җирлегенең Коминтерн торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

Карар кылдым:

1.2025 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Бураково авыл җирлегенең Коминтерн торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче студентлардан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- Коминтерн торак пункты территориясен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү (территорияне чабу, кардан чистарту))

- Коминтерн торак пунктында урман урамы буенча урнашкан Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы сугышчылары һәйкәле өчен табличканы алмаштыру (килешү буенча эш өчен түләү)

3. Бу карарны Бураково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Бураково авыл җирлеге башлыгы

Спас муниципаль районының Р.Р. Мингалиев